**СОВЕТ ГАБИШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422606 с. Габишево,
пр. Молодежный, д.1
тел: 4-46-57

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ГАБИШЕВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**
422606 Габишев авылы,
Яшьләр урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-46-57

**2020елның 7 октябре** **6 номер**

# КАРАР

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
2014 елның 12 ноябрендәге 16 номерлы
Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль
районының Габишев авыл җирлеге
советы карарына өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 12 ноябрендәге 16 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлеге советы карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

а) 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга (ата-аналарга, уллыкка алучыларга, опекуннарга, попечительләргә), шулай ук әлеге затларның 18 яшькә кадәрге балаларына салым ташламасы түбәндәге салым салу объектларына карата бирелә:

1) квартира, фатирның яисә бүлмәнең бер өлеше;

2) торак йорт яисә торак йортның бер өлеше;

гараж яисә машина урыны.

Салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә, салым түләүченең теләге буенча һәр төр салым салу объектына карата бирелә.

Салым ташламасы салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым объектына карата салым түләүче тарафыннан тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым ташламасына хокуклы затлар салым органына ташламалар бирү турында гариза, шулай ук салым ташламасына хокукны раслаучы документлар тапшыралар.

Салым ташламасы бирелә торган сайланган объектлар турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым органына үзенең сайлау буенча салым чорыннан башлап шушы объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында htth://pravo.tatarstan.ru, веб-адресы буенча Интернет Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының htth://laishevo.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлеге Советының план-бюджет комиссиясенә һәм икътисадый үсешенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**

**Лаеш муниципаль районы Габишев**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Р.Т.Хөсәенов**